
# Болгар Туган Тел



8 июнь - 14 июнь
2017 ел

I смена

**"Болгар - Туган Тел 2017" -һәркем өчен куңелендә истәлекле урын калдыра. 7 көн эчендә синең аланың, төркеменң һәм барлык атмосфера сиңа шундый якын булып китә. Һәтта кайтасы да килми... Күңелдә шундый моңсу...**
**Чыннан да, "Болгар - Туган тел" форумы - бик сихри.**

**Минем өчен, "Болгар -Туган тел" - ул кичке сонникларны дус кызың белән көлә-көлә ашау, шәмчекләрдә узеңнен хис -кичерешләреңне , көнең ничек үтте икәнен сөйләү, төркемең белән бик мавыктыргыч квест узу, Сабантуйда катнашу, кастинг узу ...**

**"Болгар - Туган тел" - ул үзеңне икенче яктан ачу. Мәсәлән, мин быел КВНда катнаштым, җанатарлардан сәхнәгә шундый энергетика килә иде, шуңа күрә, Bezz командасы үзен Югары Татар КВНщиклары кебек хис итте, рәхмәт аланыма, сез иң текә!**

**Иң мөһиме, "Болгар - Туган тел" - ул 7 көн эчендә бер команда, тату гаилә булу!**
**"Болгар - Туган тел" -чиксез мәхәббәт, мәңге дуслык һәм онытылмас мизгелләр!**

*Айназ Сөләйманова*
*Әдәби Мирас аланы, 1-нче төркем*

"Болгар-Туган тел"
Сиңа талпына күнел.
Сине ярата халык
Син бит бердән-бер байлык.

Һәр елны үтә монда
Бик матур фестивальләр
Һәм гел катнаша анда,
Төрле-төрле мираслар.

Гел-гел киләләр монда
Төрле-төрле йолдызлар.
Күңел ачып, җырлап-биеп,
Бәхет җыялар алар!

*Рамизә Хөсәенова*
*Фән-белем аланы, 2-нче төркем*
*Гөлназ Кәримова*
*Фән-белем аланы, 4-нче төркем*

# ЗУР МЕХАНИЗМГА ӘВЕРЕЛДЕК

Менә күптәннән көтелгән жәй килеп тә житте. Әле икенче генә атнасы гына булса да, Республикабыз мәктәпләренең күпчелек укучылары имтиханнар биреп йөри. Бәлки нәкъ менә шуңа көннәр дә жәйне хәтерләтмидер:кояш сирәк кенә елмая, салкын жил искәләп куя. Ләкин моңа карамастан, Болгар тыюлыгының шәхси кояшы бүген үз эшен башлап жибәрде. 8 июнь. Күпләр бу көнне көтеп алды, чөнки бүген Халыкара «Болгар-Туган тел» форумының 1-нче көне узды. Һава торышы безне сөендереп тормаса да, күңелләрдә жылылык һәм күтәренке кәеф яши!

Форумның программасы бик тыгыз һәм кызыклы икәнен аңлап алдык.Инде бүген сөрән уйлап табу, төркемнәр белән танышу, әйдаманнарның кичке чарасына бару, беренче шәмчек кебек мавыктыргыч һәм күңелле эшләр сәлкешләр жилкәләренә йөкләнгән иде. Үзем дә сәлкеш буларак аларның һәркайсына өлгерергә, һәркайсында катнашырга тырыштым. Ләкин иң истә калган бүгенге чара — ул квест булды. Гади генә түгел, ә төркемнәрнең бердәмлеген тикшерүгә багышланган квест. Беренче тапкыр күрешкән кешеләр белән бер командага әверелергә кирәк иде безгә. Әле танышуыбызга ничә сәгать, ләкин гомерлек дуслар кебек эшне башлавыбызга бик куандым. Кая карама-эш кайный иде: кем жырлый, кем бии, кем сүзләр төзи... Кыскасы, бер зур механизм бердәм эш башлап жибәрде.






«Аюлар», «Токмачлар», без «Жан кисәкләр» һәм тагын кемнәр генә юк! Бу нинди сәер атамалар дисезме? Бу-беренче бирем, исем уйлап табу иде. Бар кешенең фантазиясен эшкә жигәргә туры килде. Аннан без Динә апа һәм Рәмис абый белән санарга, Гөлшат апа һәм Дамир абый белән төрле предметларны күрсәтергә, Әнвәр абыйның кызыклы табышмакларына жавап табарга, Булат абыйны көлдерергә һ.б. биремнәр эшләргә тиеш идек.

Квест бер баланы да читтә калдырмады, һәркемгә ошады дип уйлыйм. Безнең төркем беренче килгәч-без икеләтә куандык. Алдагы чараларда да сәлкешләр шулай актив һәр креатив булсыннар иде, чөнки бу смена вакытында үз-үзеңне күрсәтеп калуга күп тырышлык куярга кирәк.

*Зөлфия Хәсәнова*

*Рухи мирас аланы, 7-нче төркем*

# Елмаеп яшик!



**Дөньяны кырыслык яулап алды, сизәсезме? Юл уртасында бер-берсе белән кычкырышкан кешеләр — бу инде нормаль куренеш. Каршыңа килгән кешедән дә нәрсә көтергә белмәссең. Заманасы кырысланды...**



**Бар дөньяны кулга алган бу начар көч белән көрәшерлек бернинди дә гаскәр җыела алмас дип уйлаган булсагыз, ашыкмагыз. Әлеге көннәрдә мин "Болгар-Туган Тел" аланында, ел саен монда җыела торган мохит белән якыннан танышуым.**

**Кешеләр, безнең киләчәк бар икән!**

**Һәм ул якты булырга охшап тора! Әлеге аланда 400ләп яшьләр җыелган һәм һәрберсе елмаеп кына аралаша. Чыккан сорауны төркем белән күмәкләшеп чишү, бер-береңә ярдәм кулы сузу - болар "Болгар-Туган Тел" аланында кешелекле шәхесләр тәрбияләнә икәнен күрсәтте миңа. Бу күренеш дөрестән дә дәртләндерә һәм әлеге яшь буын өметле дип раслый.**





**Бу көләч йөзле гаскәр дөньяга күпме булса да ямь кертәчәк. Берсүзсез! Мин моңа ышанам!**

***Азат абый Садыйков,***
***медиа үзәк***

# ИҢ КӨТЕЛГӘН ЧАРА!

**Бүген, 9 июньдә, форумның икенче көне һәм ул официаль рәвештә ачык дип игълан ителде!**



Менә аланнар сәхнә түрендә жыелды, Булат абый һәм Фаил абый кызыклы уеннар үткәрә: кем биегрәк сикерә, кем катырак кычкыра, кайсы алан иң шәбе һ.б. Болар барысы да күңелле, ләкин барча сәлкеш һәм әйдаманнар БТТның ачылу тантанасын зарыгып көтә. Аның белән бергә кадерле кунакларыбыз да килеп житәчәк.
Ниһаять! Алып баручылар сәхнәдә һәм хөрмәтле шәхесләр дә безнең күз алдында. Ногаев Камил Әсхәт улы, Афоньшина Елена Александровна, Сөләйманов Тимур Жәүдәт улы, Мусина Гөлия Фәргать кызы, Ермелин Александр Николаевич-бу безнең көтеп алган кунакларыбыз. Нәкъ менә шушы кешеләр безнең сменабыз иң шәп смена булсын өчен зур тырышлык куйган. Аларның ягымлы сүзләре күңелләргә бүгенге кояш кебек жылылык өстәде.
Безне сагынып һәм яратып килгән "Сәләт" фондының башкарма директоры Тимур абый иң көткән кунагыбыз булды. "Сез бәхетле, сез иң шәпләр. Мин сезне яратам!", - диде ул. Бу сүзләр һәр сәлкеш өчен мөһим сүзләр дип уйлыйм.
Тантаналы рәвештә гимннар астында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, "Сәләт" фонды һәм БТТның әләмнәре күтәрелде. Бу жаваплы миссия яраткан өлкән әйдаманнар, актив сәлкешләр һәм кунакларыбыз жилкәләренә йөкләнгән



иде.
Алкышлар, биюләр, балаларның шатлык тулы күзләреннән торучы бәйрәмебез азагында күмәк фото ясап, кунакларны озаттык. Безнең өчен тырышканыгыз, күп көч түккәнегез, безне ратканыгыз өчен ЗУР рәхмәт белдерәбез!

*Зөлфия Хәсәнова*
*Рухи мирас аланы, 7-нче төркем*

# Илшат Рәхимбай белән очрашу, яки "Сәлкеш, бу тормышыңа карашың нинди?"

Нәрсә генә димә, урыс халкының "сәләтле кеше һәр өлкәдә дә сәләтле" дигән әйтеме кинорежиссёр һәм оператор Илшат абыебыз Рәхимбайны төгәл сүрәтли сыман — уңган, тормышында һәрбер өлкәне татып караган шәхес, 40 кешелек аудиториянең күзләрендә чып-чын әдип булып күренде. Аның белән очрашуга килгән бер бала да сайлавы өчен үкенмәгән дип ышанабыз - дөрестән дә, очрашуда файдалы һәм кирәкле мәгълүмат алынды, режиссура хакында гына түгел, гомүмән, тормышның һәр өлкәсе дә яктыртылды. Мөгаен, сезнең очрашуны сәлкешләр күзлегеннән карыйсыгыз киләме? *Мондый момкинчелек бар!* Юкка гына утырмадык бит. Шулай итеп, режиссерыбыз һәм әдибебез белән янәдән очраштык дип хис итик тә... Ул мөһиткә чумыйк.

*Кем ул Илшат абый Рәхимбай?*

"Аны белмәгән кеше юк", - дип кырт кисмәгез - Болгар-Туган Тел аланы быел үз эченә яңа дусларын бихисап җыйган.

Илшат абый — татар режиссеры, яшь, әмма бик сәләтле кеше. Башка спикер-кунаклардан аерма булып, ул балалар белән бер дулкында аралашты - балалар аның белән рәхәтләнеп, 1 сәгать дәверендә сөйләште, берничә кызыксындырган сораулар бирде. Хәер, башта каушасалар да, Илшат абый




ягыннан активлык дулкыны нәтиҗәсендә, балалар җанланды, тагын да зуррак игътибарлык белән спикерны тыңлый башлады. Сөйләшү режиссерлык сәнгате турында чорналды - ничек клиплар, видеолар, фильмнар төшерергә, нинди материал кулланып була, монтажга никадәр вакыт китә һәм режиссёр ул вакытта нәрсәләр белән шөгыльләнә. Шулай ук, Илшат абый режиссерлыкта гына туктапып калмады - бераз тормышына карашларын тәфсилләп аңлатты, һәр кеше кылырга тиешле эшләрне билгеләде.

Аның сөйләвеннән без шуларны анладык:

— Музыка укытучысы булырга хыяланган;
— 2 югары белгечлеге бар;
— Үз-үзенә һәм башкаларга «Кем ул кеше?», « Тормыш сезне нәрсәгәдер тудырды бит, ә нәрсәгә сон?» - дигән сорауларны бирергә ярата;
— Минтимер ага Шәймиевның 80 яшьлек юбилеена клип төшергән;
Һәәәм монда кермәгән бик күп кызык фактлар.

Тулаем әйткәндә, очрашуда булган һәрбер кеше Илшат абыйдан мәгънәле һәм бик кирәкле мәгълумат ала алды. Шундый яхшы очрашуда булып кайтканыбыз өчен, зур рәхмәт сезгә, Илшат абый!

*Илзирә Гыйззәтуллина,*
*Фән-белем аланы, 6-нче төркем*

# РУХИ МИРАСТА СУПЕРМЕН ЯШИ!



**Бер кеше эчендә ничә төрле холык яшеренгән була ала икән? һәрвакыт йөзендә елмаю,ләкин кирәк вакытта кырыс була алган, үзе зур үргә менгән, ә үзе тыйнак шәхес ул — Супермен кебектер, минемчә. Безнең аланыбызда ул Супермен яши! Барыбыз да яраткан Булат абый Bravo! Әйдаманның эше тыгыз, шуңа күрә аның аз гына булган вакытын табып, интервью яздыру бәхетенә ирештем.**

*— Булат абый, сине бөтен кеше вайнер буларак белә. Шушы күп язылучысы булган, инде хәйран танылган кеше булу юлы турында сөйләп кит әле.*

**— Башта Ләйсән апагыз белән төрле "чүп-чар" төшереп йөри идек. Соңрак русча вайннарга тотындык, ләкин безнең Республикада татар теле киңрәк таралганга күрәдер инде, алар бик килеп чыкмады. Ә менә татар вайннары, Кызык-мызык, Татар малайның ярдәме белән популярлашты. Аннан инде язылучылар да артканнан арта барды. Шуның белән яңа идеяләр килеп тора.**

*— Һәр ижади кешенең үз илһам чыганагы була. Ә менә сине нәрсә илһамландыра?*

**— Беренче чиратта ул әлбәттә мәхәббәт! Бераз кычкырышып алган вакытларда булгалый. Ул чакларда идеяләр һәм илһам читтә тора миннән. Ижатка тартылу булмый һәм күңел буш була.**

*— Беркөнне Рухи аланның туры таягында "Нинди остаханәгә барасыз?"-дип сорагач, бөтен кеше синең белән очрашуга теләк белдерде. Булат абый, сине бөтен кеше белү, БТТда популяр булуга ничек карыйсың?*



**— Бер яктан карасаң,бу миңа бик ошый, ләкин икенче яктан- мине башкалардан аеруларын яратмыйм. Мин бит шундый ук кеше. Авылда үстем, шул ук ыштан, шул ук аяк киеме киеп йөрим. Бер нәрсәм белән дә аерылмыйм. 40 000 язылучым гына бар. (көлә)**

*— Әкренләп Болгар темасына да кучик. Син монда беренче тапкырмы? Гомумән, Сәләткә ничек килеп эләктең?*

**— БТТда беренче тапкыр. Монда мине төркемдә дә, тормышта да кулдашым булган Ләйсән апасы алып килде. Рухи аланга әйдаманнар житми иде һәм нәкъ шушы аланга эләккәнемә мин бик шат. Миңа монда бик ошый һәм атмосфера шаккаттыра. Ә Сәләткә килгәндә инде, Рухияталанында әйдаман булгагым бар иде.**

*— Тагын килер идеңме монда?*

**— Әлбәттә!**

*— Инде 4 көн эчендә яратып өлгергән сәлкешләреңә нинди теләкләрең бар?*

**— ЯЛКАУЛАНМАГЫЗ! Мин үзем бик ялкау кеше. Шулай ук үз-үзеңә ышану бик мөһим. Үзеңә бәяне дөрес куймасаң,аны башкалар куя. Күп очракта ул бәя түбән. Бу сыйфат булмаса, башкалар да сиңа ышанмый һәм хөрмәт итми. Үзегезгә ышаныгыз! Бары тик шул очракта гына уңышка ирешү мөмкин.**

**Менә шулай, дуслар. Бер вакытта да энергиясе бетмәс-текәлмәс Булат абыебыз эчендә нинли тыйнак, гадел Супермен яши икән. Бу очрашудан беренче караштан кешебөтенләй икенче булып күренә икәнлеген аңлалым.**

*Рәхмәт, Булат абый!*

***Зөлфия Хәсәнова***
***Рухи мирас аланы, 7-нче төркем***



**Баш мөхәррир:** Алинә апа Сысоева
Фотога төшерүче: Руслан абый Фәхретдинов
Газета чыгаруда катнаштылар: Зөлфия Хәсәнова, Азат абый Садыйков, Илзирә Гыйззәтуллина, Рәмизә Хөсәенова, Гөлназ Кәримова.

Чыгарылган: 12.06.2017

bolgar_tugantel
selet_official